| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ** |
| **ПРИКАЗ** | Казан ш. | **БОЕРЫК** |
| 03.02.2020 | | 110-п |

«Татарстан Республикасының җир өслеге су объектлары төпләрендәге утырмаларда нефть продуктларының фон микъдары» төбәк нормативларын раслау турында

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль законның 6 статьясын үтәү максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 325 номерлы карары нигезендә, хуҗалык яки башка төр эшчәнлектән әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны җайга салу максатларында **боерык бирәм**:

1. «Татарстан Республикасының җир өслеге су объектлары төпләрендәге утырмаларда нефть продуктларының фон микъдары» төбәк нормативларын кушымтага ярашлы рәвештә расларга.

2. Әлеге Боерык бастырып чыгарылган вакыттан алып вәкаләтле федераль дәүләт хакимияте органнары тарафыннан әйләнә-тирә мохит сыйфатының тиешле нормативлары кертелгәнчегә кадәр, «Татарстан Республикасының җир өслеге су объектлары төпләрендәге утырмаларда нефть продуктларының фон микъдары» төбәк нормативларына гамәлдә булу срогын билгеләргә.

3. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (М.М. Шәехов) әлеге Боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

4. Әлеге Боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары А.М.Шиһаповка йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать ресурслары
министрлыгының 2020 елның 3
февралендәге 110-п номерлы
боерыгы белән расланды

«Татарстан Республикасының җир өслеге су объектлары
төпләрендәге утырмаларда нефть продуктларының фон микъдары»
төбәк нормативлары

1. «Татарстан Республикасының җир өслеге су объектлары төпләрендәге утырмаларда нефть продуктларының фон микъдары» төбәк нормативлары Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Су объектлары төпләрендәге утырмаларда пычраткыч матдәләр микъдарына күзәтүләр оештыру һәм уздыру өлешендә су объектларына дәүләт мониторингын гамәлгә ашыру буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2014 елның 24 февралендәге 112 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы җир өсте су объектларының төптәге утырмаларының логистика сыйфатламаларын исәпкә алып һәм аларның төрле төрләре өчен эшләнде һәм Татарстан Республикасының җир өсте су объектларының төптәге утырмаларында нефть продуктларының фон микъдарын билгели (Таблица).

2. «Татарстан Республикасының җир өслеге су объектлары төпләрендәге утырмаларда нефть продуктларының фон микъдары» төбәк нормативлары су төбендәге утырмаларның нефть продуктлары белән пычрануын чикләү һәм пычрану дәрәҗәсен регламентлау, су төбендәге утырмаларның торышына мониторинг уздыру, Татарстан Республикасының җир өсте су объектлары экосистемасына тискәре йогынтыны юкка чыгару максатларында билгеләнә.

3. «Татарстан Республикасының җир өслеге су объектлары төпләрендәге утырмаларда нефть продуктларының фон микъдары» төбәк нормативлары күзәтчелек һәм контрольлек органнарына һәм хуҗалык итүче объектларга су төбендәге утырмаларның торышын бәяләгәндә, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарны бозу нәтиҗәсендә, шулай ук аварияле һәм гадәттән тыш табигый һәм техноген холыклы хәлләр барлыкка килгәндә су объектларына китерелгән зыян күләмен исәпләгәндә, әйләнә-тирә мохиткә йогынтыга бәяләү уздырганда, проект алды һәм проект документациясе составында әйләнә-тирә мохитне саклау чаралары исемлеген эшләгәндә файдалану өчен билгеләнә.

4. Су төбендәге утырмаларда нефть продуктларының фон катнашмалары елгалар һәм алардагы сусаклагычлар өчен, шул исәптән үзәнлектәге буалар, табигый һәм ясалма барлыкка килгән күлләр (казылма буалар, су баскан карьерлар) өчен, шулай ук су төбендәге төрле минераль һәм органик утырмаларның аларның гранулометрик составын (зурлыгы 0,01 мм кимрәк булган кисәкчәләр микъдарын) ачыклау нәтиҗәсендә билгеләнә торган типлары һәм органик матдә күләме өчен (кыздырганда югалту буенча) дифференциацияләнгән.

5. «Татарстан Республикасының җир өслеге су объектлары төпләрендәге утырмаларда нефть продуктларының фон микъдары» төбәк нормативлары төптәге

утырмаларда нефть продуктларының ГОСТ Р 8.589-2001 «Үлчәм алуларның бердәмлеген тәэмин итүнең дәүләт системасы. Әйләнә-тирә табигый мохитнең пычрану дәрәҗәсен тикшерүдә тоту. Метрологик тәэмин итү. Төп нигезләмәләр», ПНД Ф 16.1:2.2.22-98 «Туфракларның санлы химик анализы. Минераль, органоген, органоминераль туфракларда һәм төптәге утырмаларда нефть продуктларының масса өлешен ИК-спектрометрия ысулы белән үлчәү методикасы», ПНД Ф 16.1:2:2.2:2.3:3.64-10 (ФР 1.31.2010.07598) «Туфракларның санлы химик анализы. Туфракларның пробаларында, төптәге утырмаларда, ләмнәрдә, агынты суларның, җитештерү һәм куллану калдыклары юшкыннарында нефть продуктларының масса өлешен гравиметрик ысул белән үлчәү методикасы» нигезендә билгеләнә торган масса өлешенә тигез итеп кабул ителә.

Су төбендәге утырмаларның пробалары ГОСТ 17.1.5.01-80 «Табигатьне саклау. Гидросфера. Пычранганлыгына анализ ясау өчен су объектлары төбендәге утырмаларның пробаларын алуга карата гомуми таләпләр» һәм РД 52.24.609-2013 «Су объектлары төбендәге утырмаларда пычратучы матдәләр микъдарына күзәтүләр оештыру һәм уздыру» нигезендә алына.

Су төбендәге утырмаларның гранулометрик составы ГОСТ 12536-2014 «Грунтлар. Гранулометрик (бөртекле) һәм микроагрегат составны лаборатор билгеләү методлары» нигезендә билгеләнә. Төптәге утырмаларда органик матдә микъдары ГОСТ 26213-91 «Туфраклар. Органик матдә билгеләү методлары», ПНД Ф 16.2.2:2.3:3.32-02 «Туфракларның санлы химик анализы. Каты һәм сыек җитештерү һәм куллану калдыкларында, юшкыннарда, шламнарда, актив ләмдә, төптәге утырмаларда коры һәм кыздырылган калдык күләмен графиметрик ысул белән үлчәү методикасы» нигезендә кыздырган вакытта югалту күләме буенча ачыклана.

6. Су төбендәге утырмаларның нефть продуктлары белән пычрану дәрәҗәсен бәяләү өчен ике күрсәткеч билгеләнә: фондагыга караганда пробада булган фактик микъдарыннан тайпылган күләмен ачыклау өчен кирәкле элементның фон күләменең «югарыгы чиге», шулай ук уртача фон күләме («фон»), пычрану күрсәткечләрен исәпләү шуңа карата башкарыла (Таблица).

7. Татарстан Республикасы су объектлары төпләрендәге утырмаларның нефть продуктлары белән химик пычрану дәрәҗәсен исәпләү утырмаларның тиешле тибы өчен пробадагы элементның фактик концентрациясен фон белән чагыштыру юлы белән башкарыла.

8. Үрнәкнең су төбендәге утырмаларның теге яки бу, зурлыгы 0,01 мм кимрәк булган кисәкчәләр микъдары һәм органик матдә микъдары белән аерылып торучы тибына караганлыгын билгеләү өчен, утырмаларның гранулометрик составын һәм чыныктырганда югалткан авырлыгын ачыклыйлар, ул органик матдә пробасында процент күләмен сыйфатлый.

Әгәр су төбендәге утырмалар пробасында пычратучы матдә микъдары фон микъдары ($C_{lim}$) су төбендәге утырмаларның тиешле тибы өчен билгеләнгән (табл.) югарыгы чиген арттырып җибәрә икән, су төбендәге утырмалар пробасында нефть продуктларының чынлыктагы катнашмасының ($C_i$) фон күрсәткеченә ($C_ф$) нисбәте буларак пычрану коэффициентын ($К_з$) исәплиләр, түбәндәге формула буенча (1):

$$К_з = C_i / C_ф \qquad (1).$$

Бу вакытта түбәндәге классификация кертелә: $К_з<3$ – уртача пычраклык коэффициенты, $3\leК_з<6$ – шактый, $К_з\ge6$ – югары.

9. Су төбендәге утырмалар пробасында нефть продуктларының микъдары фон күләменең су төбендәге утырмаларының тиешле тибы өчен билгеләнгән югарыгы чигеннән артып китмәсә, су төбендәге утырмалар пычранмаган булып санала.

Таблица

Татарстан Республикасының җир өслеге су объектлары төпләрендәге утырмаларда нефть продуктларының фон микъдары төбәк нормативлары, мг/кг

| Төптәге катламнар характеристикасы | Фон, $С_ф$ | Югарыгы чиге, $C_{lim}$ |
|---|---|---|
| Елгалар һәм сусаклагычлар | | |
| Органик матдә микъдары 8%тан ким, кисәкчәләр микъдары <0.01 мм 30%тан кимрәк | 45 | 100 |
| Органик матдә микъдары 8%тан ким, кисәкчәләр микъдары <0.01 мм 30%тан күбрәк | 65 | 115 |
| Органик матдә микъдары 8%тан артык, кисәкчәләр микъдары <0.01 мм 30%тан кимрәк | 160 | 305 |
| Органик матдә микъдары 8%тан артык, кисәкчәләр микъдары <0.01 мм 30%тан күбрәк | 180 | 475 |
| Күлләр | | |
| Органик матдә микъдары 12%тан ким, кисәкчәләр микъдары <0.01 мм 50%тан кимрәк | 90 | 195 |
| Органик матдә микъдары 12%тан ким, кисәкчәләр микъдары <0.01 мм 50%тан күбрәк | 220 | 345 |
| Органик матдә микъдары 12%тан артык, кисәкчәләр микъдары <0.01 мм 50%тан кимрәк | 315 | 460 |
| Органик матдә микъдары 12%тан артык, кисәкчәләр микъдары <0.01 мм 50%тан күбрәк | 320 | 510 |